**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**21 ноябрь, 2023 ел** **№ 358**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләрен раслау турында» 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләрен раслау турында» 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карарына (28.03.2018 №208, 29.10.2018 №257, 14.12.2018 №268, 17.04.2019 №292, 19.03.2020 №366, 02.04.2021 №64, 06.08.2021 №98 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 6 бүлегендәге 6.6 - 6.9 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район Советы депутаты түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләре ширкәтеннән һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә теркәлгән профсоюздан тыш), федераль законнарда башкасы каралмаган булса яисә федераль

законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса;

2) укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү. Шул ук вакытта укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

3) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтчелек советлары, башка коммерциясез хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләре составына керергә.

6.7. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.

6.8. Район Советы депутаты вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлеме;

2) үз теләге белән отставкага китүе;

3) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылса;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

5) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керү;

6) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына күчүе;

7) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил дәүләте - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданлыгы туктатылу, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт яисә Россия

Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы документы булу, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;

8) сайлаучылар тарафыннан район составына керүче җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак чакыртып алу;

9) район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә җирлек башлыгы яки җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

10) хәрби хезмәткә чакырылу яисә аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелү;

11) федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.

6.9. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта, депутатның, муниципаль вазыйфаны биләүче башка затның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

6.10. Район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, тиешле җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан күрсәтелгән орган бер ай эчендә район Советы составына башка депутатны сайларга тиеш.»;

1.2. 2 нче кушымтаның 3.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:

17) муниципаль янгыннан саклану оешмасы төзи.»;

1.3. 3 нче кушымтаның 1.9 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов